АЛЕКСЕЕВСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
АЛЕКСЕЕВСК
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14.02.2020 п.г.т. Алексеевское 298

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә торак урыны мәйданын бирү һәм исәпкә алу нормасын билгеләү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 50 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

**Алексеевск муниципаль районы Советы карар кылды:**

1. Социаль наем шартнамәсе буенча һәм Дәүләт торак программалары буенча гаиләнең бер әгъзасына 18 кв.метр күләмендә торак урыны мәйданы, әмма ялгыз яшәүче граждан өчен кимендә 33 кв. метр һәм ике кешедән торган гаилә өчен торак урыны гомуми мәйданының 42 кв. метрыннан да ким булмаган күләмдә торак урыны бирү нормасын билгеләргә.

2. Торак урыны мәйданының исәпкә алу нормасын билгеләргә, аннан чыгып, гражданнарның торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында торак урыны мәйданының гаиләнең бер әгъзасына 18 кв.метрдан да ким булмаган гомуми мәйданы белән тәэмин ителеше дәрәҗәсе билгеләнә.

3. Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск муниципаль районында торак урын мәйданының исәпкә алу нормасын билгеләү турында» 2007 елның 19 ноябрендәге 280 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Советының экология, җир мәсьәләләре, төзелеш, ТКХ һәм транспорт буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

**Алексеевск муниципаль**
**районы башлыгы,**
**Совет рәисе** **С.А. Демидов**